12+

Бәхет! Шатлык! Иминлек!

# Ярмәкәй яңалыклары

ҖОМГА, 31 май, 2024 ел №22 (8989)

Иҗтимагый-сәяси газета 1935 елның апреленнән башлап чыга erm-news.ru

● КРЕСТЬЯННАР ЭШЛӘРЕ

## Чәчү соңгы гектарларда. Азык хәзерләү башланды

Район игенчеләре финиш сызыгына чыкты. Язгы кыр кампаниясе тәмамлануга якынлаша. Соңрак карабодай культурасын чәчәсе кала.

Район хакимиятенең авыл хуҗалыгы бүлеге мәгълүматлары буенча, чәчү 39561 гектарда үткәрелгән, бу язгы культураларның планлы күләменең 96 проценты.

Хәзер аграрийлар шикәр чөгендере кырларында беренче химик утау алып бара. Шулай ук язгы бөртекле культураларны һәм көнбагышны корткычларга һәм авыруларга каршы химик эшкәртү һәм утау башланды.

Ә "Северная Нива Башкирия" җәмгыятендә инде көзге арыштан сенаж салуга керештеләр. Бүгенге көндә 1000 тоннадан артык яшел масса салынган.

## Хезмәт ярышы бара

Югары сыйфатлы һәм оптималь вакыт аралыгында язгы кыр эшләрен уңышлы башкару, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, авыл хуҗалыгы техникасын нәтиҗәле куллану һәм хезмәт дисциплинасын ныгыту максатларында район хакимияте башлыгы карары белән авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм механизаторлары арасында хезмәт ярышы игълан ителде.

Хуҗалыклар арасында агротехник таләпләрне һәм нигезле чәчү әйләнешен үтәп, язгы кыр эшләрен оптималь вакыт аралыгында уңышлы тәмамлаган предприятиеләр җиңүче дип таныла. Шул ук вакытта чәчү өчен дүртенче репродукциядән түбән булмаган орлыклар кулланганнар һәм чәчү мәйданнарының ким дигәндә 10% элиталы орлыклар белән чәчсәләр. Чәчүлекләрнең гомуми структурасында көнбагыш астындагы мәйданнар өлеше 13% тан артмаска тиеш. Көзге эшләрне исәпкә алып, 1 гектарга 50 килограммнан да ким булмаган күләмдә минераль ашламалар кертелергә тиеш. Тагын бер мөһим шарт – җитештерү травматизмы һәм янгын очракларына юл куймау.

Хезмәт көндәшлегенә йомгак комиссия чәчүлекләрне кабул иткәннән соң ясалачак. Җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата бүләкләр белән билгеләнәчәк.

Механизаторлар арасында иң югары күрсәткечләргә ирешкән, хәвефсезлек техникасы һәм хезмәт дисциплинасы кагыйдәләрен бозуга юл куймаган кешеләр җиңүче дип таныла.

Алар район хакимиятенең Рәхмәт хатлары һәм акчалата бүләкләү белән билгеләнәчәк.

● СОЦИАЛЬ СӘЯСӘТ

## Торак шартларын яхшыртуга

**Торак сатып алуга социаль түләү бирү турында сертификатны А.Әминевага тапшырдылар. Бу хакта район хакимиятенең рәсми сайтында хәбәр иттеләр.**



– Үз торак белән тәэмин итү – кешеләр өчен бик мөһим мәсьәлә. Чөнки торак тормышыбызда күп нәрсәне билгели, бу – тотрыклылык һәм иртәгәсе көнгә ышаныч, – дип билгеләп үтте район хакимияте башлыгы Илшат Райманов.

Әлеге сертификат "БРда инвалидларга социаль ярдәм турында"гы Башкортстан Республикасы законына ярашлы рәвештә торак сатып алуга социаль түләү алырга мөмкинлек бирәчәк. Закон проекты буенча, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә алынган һәм хроник авыруларның авыр формаларыннан интегүче инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр торак сертификаты белән расланган төзекләндерелгән торак урынын сатып алуга социаль түләүне бер тапкыр сайлап алу юлы белән торак урыннары белән тәэмин итү хокукына ия.

● МӘГАРИФ

## *Үзгәрешләр вакыты һәм яшьлек тантанасы*

### Район мәктәпләрендә соңгы кыңгырау чыңлады

**Барлык чыгарылыш сыйныф укучылары өчен бу дулкынландыргыч мизгел иде. Ярмәкәй мәктәбендә өч тугызынчы һәм унберенче сыйныф укучылары чара геройлары булды.**

Тантаналы линейкада алар янында яраткан укытучылары, әти-әниләре, дуслары бар иде. Булачак студентларга карата мәктәп һәм район җитәкчелегеннән күп кенә үгет-нәсихәт сүзләре яңгырады. Мәктәп директоры Филүз Шәмсуллин, район хакимияте башлыгы урынбасары Татьяна Головина, мәдәният, спорт һәм яшьләр сәясәте бүлеге башлыгы Ирина Рәхмәтуллина, сыйныф җитәкчеләре Рина Имаева, Гүзәл Госсамова, Резидә Гайфуллина, Гүзәл Галиуллина, беренче укытучылары Айгөл Таҗиева һәм Зимфира Каюмова укучыларга яхшы теләкләрен җиткерделәр. Аларның иң мөһиме – тормышта беренче һәм иң катлаулы сынауларны үтү: имтиханнар һәм югары уку йортларына керү. Ә аннары инде дипломлы белгечләр булып туган якларына кайтырга, анда аларны түземсезлек белән көтәләр.

◂ Ахыры 5нче биттә.

● БЕЗНЕКЕЛӘРНЕ БЕЛЕГЕЗ!

## *Уңышлы йөгерү*

**Илина Габдуллина һәм Егор Головин "ЗаБег.РФ" җиңел атлетика киңкүләм стартында катнаштылар. Бу илдә иң масштаблы спорт чараларының берсе. Киңкүләм мәгълүматлары буенча, анда быел 150 мең кеше катнашты. Уфада стартка 3200 кеше чыкты.**




Катнашучылар 1, 5, 10 һәм 21 километр дистанцияләрдә, шәһәрнең үзәк урамнары буенча уза торган трассада ярышты.

Безнең яшь спортчылар әлеге бәйгедә яхшы нәтиҗәләр күрсәттеләр. Укучыларның тренеры Николай Федоров сүзләренчә, Егор топ-10га эләккән, ә Илина үз яшь төркемендә беренче урынны алган.

## *Волейболчылар лидерлар өчлегендә*

**Уфа шәһәрендә кызлар командалары арасында Башкортстан Республикасы "Мәктәп волейбол лигасы"ның финал этабы узды. Анда иң көчле җиде команда катнашты.**



Ярышлар нәтиҗәләре буенча безнең волейболчылар мактаулы икенче урынны алды (узган елдагы кебек үк), беренче нәтиҗәне яңауыллылар күрсәтте, өченче урынны Дуван районы спортчы кызлары яулады.

Безнең команда кубок, медальләр һәм өч профессиональ туп алу сертификаты белән бүләкләнде. Яшь спортчы кызларны һәм аларның тренерын, бер үк вакытта Ярмәкәй мәктәбенең физкультура укытучысы Фәттахов Рәзил Рузил улын котлыйбыз!



**Бүген республикада** * МӨҺИМ * КЫЗЫКЛЫ * ФАЙДАЛЫ

# Су коену сезонының биш кагыйдәсе. Пляжда нәрсәләр эшләргә ярамый?

***Җәй башлануга һәм су коену сезоны ачылуга кадәр бик аз вакыт кала. Статистика күрсәтүенчә, җәйге ял вакытында күпчелек бәхетсезлек очраклары кешеләрнең суда үлеме белән бәйле, шуңа күрә тагын бер тапкыр хәвефсезлек кагыйдәләре турында искә төшерәбез.***



**2023 елның 1 июненнән 31 августына кадәр Башкортстанда суда 86 кеше һәлак булган, шуларның 9ы — балалар. Барыннан да ешрак кешеләр су коену өчен җиһазландырылмаган урыннарда һәм исерек килеш суга керү сәбәпле батып үлгән.**

### 1. ТЫЕЛГАН УРЫННАРДА СУ КОЕНМАГЫЗ

Су җавапсызлыкны гафу итми. Беркайчан да, бернинди шартларда да су коену тыелган урыннардагы пляжны сайламагыз, һәм бигрәк тә анда балаларны алып бармагыз. «Су коену тыелган» дигән такта юктан гына куелмый, аны кешегә хәвеф янаган урында урнаштыралар. Көчле агым, су чоңгыллары, суүсемнәре, яр буендагы комда табылган паразитлар — болар барысы да пляжны ябу өчен сәбәп.

Республикада хәзер тыю аншлагларын азрак урнаштырырга, ә ял итү урыннарын күбрәк тәэхкиләндерергә тырышалар. Идел буе федераль округында Башкортстан ачык пляжлар саны буенча лидер булып тора: биш ел эчендә аларның саны 68дән 150гә кадәр арткан, быел исә 200 пляж ачарга планлаштыралар.

Беренче чиратта урындагы халык күпләп ял иткән урыннар җиһазландырыла: яр буен һәм суга керү урынын чистарталар, пляжны киңәйтәләр, коткаручыларның кизү торуын тәэмин итәләр. Башкортстанның Гадәттән тыш хәлләр буенча дәүләт комитеты сайтында махсус интерактив карта бар, анда якындагы җиһазландырылган пляжны табарга мөмкин (portal.introgis.com). Картада кешеләрне кабул итәргә әзер булган ял итү урыннары яшел төстә билгеләнә. Шунда ук суда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре һәм суга батучыны коткарырга туры килсә, ничек эш итәргә кирәклеге турында җентекле күрсәтмә урнаштырылган.

### 2. Балаларны караучысыз калдырмагыз

Әгәр дә пляжга бала белән барасыз икән, аны бер секундка да игътибарсыз калдырмагыз. Су коенганда балалар һәрвакыт ата-аналарның күз уңында булырга тиеш, ә иң яхшысы — өлкәннәрнең суда алар янында булуы. Ял итү өчен төбе чиста булган сөзәк яр буендагы пляжны сайлагыз. Йөзә белмәгән балаларга өлкәнрәкләреннән ераграк тору хәерле. Суда бик сак уйнарга кирәклеген аңлату зарур, бер-беренне «батырырга», шулай ук шаярып ярдәмгә чакырырга ярамаганлыгын төшендерегез. Бу гомер өчен куркыныч!

Кеше, шул исәптән бала да, батканда, тыпырчына, кычкыра, ярдәм сорый, дигән фикер бар. Чынлыкта, коткаручылар билгеләвенчә, суга батучы еш кына бер аваз да чыгармый, ул тиз һәм тавышсыз бата. Чөнки бөтен көче кычкыруга түгел, ә сулыш алуга китә. Кеше су өстендә кулларын болгамый, ә, су өстендә калырга тырышып, аннан этәрелергә тырыша. Читтән бу уен кебек тоелырга мөмкин.

Шуңа күрә, әгәр дә сез баланың еш авызын ачуын, башын артка ташлавын, чәчен йөзеннән сыпырмавын, карашы «пыяла» кебек булуын күрәсез икән, шунда ук ярдәмгә ташланыгыз. Бәлки ул, чыннан да, уйныйдыр, ләкин аның янына барып, чынбарлык хәлне ачыклау хәерлерәк.

### 3. ӨРЕП КАБАРТЫЛУЧЫ МАТРАСЛАРДА ЙӨЗМӘГЕЗ

Өреп кабартылучы матрасларда татлы эчемлек суырып, тыныч кына судан йөзеп барган күренешләрне кино артистларына калдырыгыз. Ачык сулыкларда ял итүчеләр өчен бу катгый тыела. Матрасны бары тик яр буенда кояшта кызыну өчен генә кулланырга мөмкин. Суда йөзгәндә камера шартлавы яки аның тыны чыгу гына куркыныч тудырмый, ә кискен җил искәндә кабартылган матрас, җилкәнле көймә кебек, ярдан бик тиз ераклаша, өстәвенә, җил һәм дулкыннар аны җиңел генә әйләндереп капларга да мөмкин. Кайвакыт матрастагы яки резина түгәрәктәге кешене дулкыннар ярдан еракка алып китә, аңа ярдәмгә туганнары ташлана, ләкин берничек тә куып җитә алмыйлар һәм хәлдән таялар. Бу очракта берьюлы берничә гомер куркыныч астына куела. Үзегезне һәм якыннарыгызны саклагыз!

### 4. ПЛЯЖДА СПИРТЛЫ ЭЧЕМЛЕКЛӘР КУЛЛАНМАГЫЗ

Пляждагы исерек кеше — тирәюньдәгеләр өчен бер бәла. Өстәвенә, җәмәгать урыннарында алкоголь кулланган өчен 500-1,5 мең сум күләмендә штраф яный (Русия Административ хокук бозулар кодексының 20.20 маддәсе). Хәвефсезлек турында сөйләгәндә исә, эсседә спиртлы эчемлекләр кулланудан бөтенләй баш тарту хәерле, чөнки терморегуляция бозыла, организм югары йөкләнеш кичерә. Әгәр дә инде су коенырга да уйласак, эсседән салкынга кискен керү өянәккә китерергә мөмкин, чөнки йөрәк һәм кан тамырлары болай да чиктән тыш киеренкелектә эшли. Эсседә иң яхшы эчемлек — үлән чәе, җиләк морсы яки гади чиста су. Пляжга аек килеш барыгыз, кояшта янмас өчен иртән яки кич килү яхшырак. Баш киеме киярә дә онытмагыз.

### 5. ПЛЯЖ ТЕРРИТОРИЯСЕН ПЫЧРАТМАГЫЗ

Су коену сезоны башланыр алдыннан пляжлар кешеләрне кабул итүгә җитди әзерләнә: водолазлар су төбен куркыныч әйберләрдән — пыяладан, ботаклардан, пластиктан чистарта; санитар табиблар — ярны, су коенучылар эчәк инфекцияләре йоктырмасын өчен суны һәм комны тикшерә. Пляж сезон ахырына кадәр шулай чиста булып калырга тиеш, шул исәптән безнең ярдәм белән дә. Пластик савыт-сабаны һәм пыяла шешәләрне үз артыңнан җыю, сукбай хайваннарны җәлеп итмәс өчен чүпчарны куак астына түгел, ә якындагы чүп савытына салу — болар барысы да пляжны чиста тотарга ярдәм итүче һәм аны хәвефсез итә торган элементар кагыйдәләр.

**Материалларны «Башкортстан Республикасы» нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе редакциясе әзерләде. Язмалар буенча тәкъдимнәрегезне axmetshina.v@rbsmi.ru адресына җибәрегез, телефон: (347) 272-92-61.**


## Кадерле газета укучылар!

***2024 елның икенче яртыеллыгына язылу кампаниясе дәвам итә.***

Газетаның басма версиясенә язылу: • аена – 161,65 сум; • яртыелга – 969,90 сум; • бер елга – 1742,88 сум. Газетаның электрон версиясе – 128 сум, 768 сум, 1536 сум. Редакциядә язылу бәясе: • аена – 130 сум; • ярты елга – 780 сум; • бер елга – 1560 сум тәшкил итә.

***Безнең белән калыгыз һәм яңалыклардан хәбәрдар булыгыз.*** Реклама хокукында.

**Компания ООО «Башнефть-Добыча» приглашает на работу:**

- Оператор по добыче нефти и газа
- Электромонтер по ремонту и обслуживанию электрооборудования
- Трубопроводчик линейный
- Оператор товарный

**Наши условия:** официальное трудоустройство, стабильная заработная плата, полный социальный пакет.

По вопросам трудоустройства обращайтесь:

**+7 (347) 214-49-95**

Эл. адрес: rezume_bnd@bn.rosneft.ru

Реклама



ОЕШТЫРУЧЫЛАР: 1.Башкортстан Республикасының матбугат һәм киң мәгълүмат чаралары агентлыгы (450077, Башкортстан Республикасы, Уфа шәһәре, Киров урамы,45).
2. “Башкортстан Республикасы” Нәшрият йорты Башкортстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе (450079, Башкортстан Республикасы, Уфа шәһәре, Октябрьнең 50 еллыгы урамы,13).

Газета Башкортстан Республикасында элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм киңкүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсе тарафыннан теркәлгән. ТЕРКӘҮ САНЫ: ПИ № ТУ02-01467 (07 октябрь, 2015 ел).

Баш мөхәррир Р.Ә.Рәхмәтуллин.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: 452190, Башкортстан Республикасы, Ярмәкәй районы, Ярмәкәй авылы, Совет урамы, 59.
НӘШРИЯТ АДРЕСЫ: “Башкортстан Республикасы” Нәшрият йорты БР ДУП 450079, Башкортстан Республикасы, Уфа шәһәре, Октябрьнең 50 еллыгы урамы,13.

Кул кую вакыты — 12 сәг. 00 мин.
Кул куелды — 12 сәг. 00 мин. (30.05.2024)

ТЕЛЕФОННАР: Мөхәррир — 2-25-60; җаваплы сәркатип— 2-21-62; корреспондентлар, фотокорреспондент — 2-24-61; бухгалтерия, реклама бүлеге — 2-24-64 /факс/.
E-mail: erm-news@rambler.ru

Бәясе ирекле.

Газета Башкортстан Республикасының “Башкортстан Республикасы” Нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе филиалы Бәләбәй мәгълүмат үзәгендә басылды (452005, Башкортстан Республикасы, Бәләбәй шәһәре, Мало-Луговая урамы, 53 а). Тел.: 4-16-94.
ТИРАЖЫ 291 данә.
КҮЛӘМЕ ике басма бит.
Индексы ПО564.
ЗАКАЗ № 930


БЕЗНЕҢ РЕКВИЗИТЛАР:
Башкортстан Республикасының “Башкортстан Республикасы” Нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе филиалы Ярмәкәй мәгълүмат үзәге
ИНН 0278066967 КПП 022143001
Наименование банка:
ПАО «БАНК УРАЛСИБ» г.Уфа
р/с 40602810900200000002
к/с 30101810600000000770
БИК 048073770 ОКПО 02446527

Һәр җомга көн рус һәм татар телләрендә чыга.
Редакциянең басылып чыккан мәкаләләр авторларының фикере белән һәрвакытта да килешү зарури түгел.
Автор бирелгән материалларның нигезле һәм дөрес булуы өчен җавап бирә.
Рекламага заказлар эш көннәрендә көн саен кабул ителә.
Котлаулар газета чыгарга биш көн кала кабул ителә.

● ЯШЬ КАДРЛАР

# Сәламәт елмаю бүләк итә

**Ярмәкәй авылыннан Альзана Харисова бер ел элек район хастаханәсенең стоматология бүлеге бусагасын табиб-стоматолог буларак атлап керде**



Дипломлы белгеч БДМУны тәмамлаганнан соң үз районына кайта. Белемне коммерция нигезендә алган, һәм максатчан укытуда кебек эшләү бурычы юк. Ләкин кыз башта ук үзенең кире кайтачагын белгән. Ә ул билгеләнгән юлдан тайпылмый. Бу безнең аның белән сөйләшүебездән ачыкланды. "Земский доктор" программасы да зур роль уйный, аның кысаларында авыл җирлегеннән яшь табиб, ким дигәндә биш ел медицина учреждениесендә эшләү шарты белән, 1,5 млн сум күләмендә түләү алачак.

Үзенең булачак һөнәрен Альзана балачакта ук билгеләли. Теш табибына беренче тапкыр баргач, аңа игелекле табиб та, тирә-юньдәге хәл дә тәэсир итә. Шул вакыттан бирле ул курчакларның, дус кызларының тешләрен дәвалый башлый.

Ярмәкәй урта мәктәбен тәмамлагач, чыгарылыш укучысы алдында сайлау тора: БДМУда педиатрлыкка максатчан юнәлеш буенча укырга яки Санкт-Петербург югары уку йортында фармацевт белгечлегә алырга. Сүз уңаеннан, әнисе Альбина Нәкип кызы район даруханәсендә фармацевт булып эшли. Кызы аның эзе буенча барыр дип уйлаган булган. Ләкин Альзана үз хыялын тормышка ашырырга тели, һәм әти-әнисе, кызының максатчанлыгын күреп, аңа ярдәм итә.

Студент кыз практикасын район хастаханәсендә үткән. Үзенең остазлары Фларида Хөснуллина, Сөнәгать Габдуллин, Анатолий Кузнецов, Лариса Хөснетдинова турында җылылык белән сөйли. Уку бер нәрсә, ә практика бөтенләй башка, ди. Мондый ярдәмчел, игелекле өлкән хезмәттәшләр янында булу яхшы.

Узган елның июлендә ул диплом белән өенә кайткан. Ике атнадан соң ук үзенең хезмәт биографиясен башлаган. Параллель рәвештә ординатурада укый, гомуми практиканың табиб-стоматологы була.



Альзана Илдар кызы көненә ун пациент, шул исәптән балаларны да кабул итә. Моннан тыш, медицина хезмәткәрләре бригадасы составында ФАПларга чыга, анда медицина тикшерүе үткәрә. Ял көннәрендә, кичләрен ашыгыч чакырулар да була. Мондый һөнәрне ул үзе сайлаган һәм үкенми. Аңа кешеләргә авыртудан котылырга ярдәм итү, аларга сәламәт елмаю бүләк итү шатлык китерә.

Балалар белән ничек мөгамәлә итәсез дигән сорауга ул гади генә: "Мин алар белән уртак тел табам".

Минем өчен җавап ачык иде инде: кабинетка кергәндә, үз куззләрем белән креслодан торып, киң елмаеп чыгып киткән кыз баланы күрдем...

**Надежда ПОПОВА.**
**Мансур АРСЛАНОВ фотосы.**

# "Ватанны сакларга телим", – ди

**Яңа Шах авылыннан хәрби хезмәткә чакырылучы Ранис**

Бер көн Ярмәкәй районы егетләре комиссия үтте. Гражданнарны хәрби хезмәткә чакыру бүлеге начальнигы ярдәмчесе Нәзилә Кашапова әйтүенчә, чакырылыш комиссиясе утырышына 20ләп кеше килде. Быел алар уку йортларын тәмамлыйлар. Диплом яклаганнан соң аларны армиягә алалар.



Ярмәкәй авылы егете Руслан Уфа урман-техник техникумында укый. Аның сүзләренчә, ул спецназда яки ВДВда хезмәт итәргә тели. Сәламәтлеге яхшы, спорт белән дус, физик яктан әзер.

Ранис Бәләбәй авыл хуҗалыгы техникумында автомеханик белгечлеге ала. Теләк белән хезмәт итәргә барачагын билгеле. Аның әтисе бер ел элек Оборона министрлыгы белән махсус хәрби операция зонасында хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән. Ул тимер юл подстанциясендә өлкән электромеханик булып эшләгән. Ил өчен авыр вакытта дүрт бала атасы аны якларга китә. Шуңа күрә Ранисның үрнәк алырлык кешесе бар.

**Надежда ПОПОВА.**
***Автор фотосы.***

● СӘЛАМӘТЛЕК САГЫНДА

# Кабатлау – белгәннәрне камилләштерү

**Ярмәкәй район үзәк хастаханәсендә авыруда хәвефле инфекция – холера шартлы рәвештә ачыкланган очракта медицина-профилактика һәм эпидемиягә каршы чараны эшләп чыгу буенча ел саен уза торган күнегүләр үтте.**

Анда хастаханәнең медицина хезмәткәрләре, Роспотребнадзор идарәсе Бәләбәй территориаль бүлегенең I разрядлы өлкән белгече Рафаэль Сәмигуллин катнашты. Өйрәнүләргә Туймазы, Бәләбәй шәһәрләрендәге ФБУЗ (БРда Гигиена һәм эпидемиология үзәге) табиб-эпидемиологы Эльвина Захарова, ашыгыч ярдәм автомобиле, гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм полиция хезмәткәрләре җәлеп ителде.






Легенда буенча, авыру илгә Һиндстаннан самолет белән кайткан һәм шунда ук поликлиникага, ашыгыч ярдәм кабинетына кабул итүгә килгән.

Укулар барышында дәвалау учреждениесе медицина персоналының, табиб-инфекционистның дөрес гамәлләренә, барлык санитар нормаларны үтәүгә, кирәкле саклану һәм дезинфекцияләү чараларының булуына игътибар бирелде. Шартлы рәвештә чирне йоктырган авыруны хастаханәгә салдылар.

Тренировкаларга йомгак ясаганда өйрәнүләрдә катнашучыларның грамоталы гамәлләре билгеләнде.

**Үз хәбәрчебез.**

**Рәсемнәрдә:** район хастаханәсендә өйрәнүләр.
**Мансур АРСЛАНОВ фотосы.**

● РАЙОН ПРОКУРАТУРАСЫННАН

# Хокук бозуларны бетерү буенча контроль

**Башкортстан Республикасы буенча Русия Федерациясе Пенсия фонды һәм социаль иминият бүлеге тарафыннан балалары булган гаиләләрне, шулай ук инвалидларны техник реабилитация чаралары белән тәэмин итү турындагы закон таләпләренең үтәлешен тикшерү нәтиҗәләре буенча, инвалидларны техник реабилитация чаралары, протез-ортопедик әйберләр белән тиешенчә тәэмин итмәү өлешендә федераль закон бозулар ачыкланды.**

Тикшерү нәтиҗәсендә, закон таләпләрен бозып, районның ике кешесе, аларның берсе балигъ булмаган бала, шәхси реабилитация программасына ярашлы рәвештә протез-ортопедия эшләнмәләре белән тәэмин ителмәгәнлеге ачыкланды.

РФ Пенсия фонды һәм социаль иминият бүлеге идарәчесе адресына хокук бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр кертелде.

Тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча прокурор таләпләре канәгатьләндерелде, хокук бозуларны бетерү чаралары күрелде, сатып алулар үткәрелде, инвалидларны тәэмин итү максатыннан протез-ортопедик әйберләр ясау процедурасы оештырылды.

Район прокуратурасы хокук бозуларны тулысынча бетерүне контрольдә тота.

**Илнур СӘЙФУЛЛИН,**
**район прокуроры.**

● ЯРЫШЛАР

# Юнармия алга!

**Ярмәкәй авылының балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе базасында “Зарница 2.0” республика хәрби-спорт уенының зона этабы узды**

Кунакчыл җиребезгә лидер команда булыр өчен көрәшкә Туймазы, Шаран, Чишмә, Благовар районнарыннан һәм Октябрьский шәһәреннән килделәр.

Яңа, заманча җиһазлар һәм “Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру” федераль программасы кысаларында төзелгән мәйданчыкта барысын да хакимият башлыгы Илшат Райманов, район хакимиятенең мәдәният һәм яшьләр сәясәте бүлеге башлыгы Ирина Рәхмәтуллина, Ярмәкәй районында “Беренчеләр хәрәкәте” эшен оештыру буенча белгеч Оксана Усманова сәламләде, көрәштә уңышлар теләде.

Илшат Әмир улы үз чыгышында билгеләп үткәнчә, киләчәктә Ватанны саклаучылар булыр өчен, чарада катнашучыларның өстенлеге спорт, физкультура белән актив шөгыльләнү булырга тиеш.



Русия һәм Башкортстан гимннары яңгырады. Ярышлар ачык дип игълан ителде. Ул көнне һава торышы да сөйләшеп куйган кебек, кояшлы, җылы булып чыкты, һәм команда әгъзалары программа биремнәрен рәхәтләнеп һәм кәеф белән үтәде. Барысы да сафка әзерләнүдән башланды. Юнармиячеләр, хәрби солдатлар кебек, сафта йөрделәр, командирның башка командаларын үтәделәр. Аннары гомуми гаскәр саклану комплекты киделәр. Монда эшләрен тәмамлагач, команда әгъзалары вакытка Калашников автоматын сүтеп җыю белән шөгыльләнде, магазинны патроннар белән җиһазландыруда ярыштылар. Кыскасы, армия тормышындагы кебек.

Ә аннан соң көч, чыдамлык, төгәллек буенча биремнәр булды. Балалар күнегүләр ясап, киртәләр полосасын үтеп, пневматик коралдан атып карады. Һәр төрдә малайлар һәм кызлар команданың бердәм эшчәнлеген күрсәтте, барлык этаплар да лаеклы, дустанә үтте. Һәр үтәлгән бирем өчен барысының да исәбенә баллар суммасы тупланды.

Нәтиҗә ясап, ДЮСШ белгечләре, тормыш эшчәнлеге нигезләре фәне укытучыларыннан торган судьялар коллегиясе призерларны һәм җиңүчеләрне игълан итте.

Урта яшь төркемендә беренче урынны Шаран районы юнармиячеләре, икенче – Туймазы районы һәм өченче – Чишмә командасы алды.

Өлкән яшь төркемендә призлы урыннарны, тиешлечә, Ярмәкәй, Туймазы һәм Благовар районнары укучылары яулады.

**Үз хәбәрчебез.**

**Рәсемнәрдә:** хәрби-спорт уены фрагментлары.

**Мансур АРСЛАНОВ фотосы.**








● ПИОНЕРЛАР КӨНЕНӘ

# “Әзер бул!” девизы астында

**Бу май көннәрендә Бөтенсоюз пионер оешмасы оешуга 102 ел тулды. Явыз ниятле кешеләр бүген безнең үткәнебезне күпме генә тәнкыйтьләмәсен, пионер хәрәкәте ил тарихында тулы бер эпоханы үз эченә алган, хәзерге вакытта да яшәвен дәвам итә.**

Пионер, пионер отряды, пионер дружинасы! Пионер авазы “Әзер бул!”. Бу төшенчәләр белән бүген 40 һәм аннан да күбрәк яшьтәгеләрнең балачагы бәйле. “Пионер” сүзе астында барысы да кызыл пионер галстугын, дружинаның кызыл байрагын, тавышында калтырап әйтелгән тантаналы вәгъдәне, беренче пионер салютын, учак янында җырлар белән походларны, кызыклы кешеләр белән очрашуларны һәм башка күп нәрсәне искә ала.



Илебезнең үткәненә тирән хөрмәт күрсәтеп, Пионерлар көнен бәйрәм итү кысаларында Приют бистәсендә ветераннар советы активистлары Суккул авылы урта мәктәбе укучылары белән очрашуга килде. Пионер-ветераннар кызыл галстуклар һәм пилоткалар киеп, авыл клубының актлар залына быргы һәм кызыл байрак белән барабан тавышы астында җырлап керделәр һәм сәхнәгә тезелделәр. Тантаналы чара авылыбызның хәзерге үсеп килүче буыны өчен ветераннар тарафыннан әзерләнгән речевкадан башланды. Элеккеге пионерлар, алар арасында Рождественка авылыннан чыккан кешеләр, балаларга үзләренең бәхетле пионер балачагы атмосферасын җиткерергә тырыштылар: шигырьләр укыдылар, ретро-җырлар җырладылар, ә залда утырганнар үзешчән артист-ветераннарга кушылып җырлады һәм алкышлады. Бәйрәмнең кульминациясе булып чуваш хатын-кыз фольклор төркеменең якты, колоритлы милли костюмнарда чыгышы булды.

Суккуллылар да бурычлы калмады. Кунаклар өчен экскурсия оештырылды. Аның барышында легендар 112нче башкорт кавалерия дивизиясенә багышланган хәрби-тарихи экспозиция, аның формалашу тарихы, Суккул һәм башка авыллардан чакырылган сугышчы-кавалеристлар, район халкының Бөек Ватан сугышы елларында кавалеристларны мөлкәт, азык-төлек һәм җиһазлар белән тәэмин итүдә катнашуы турында таныштылар. Чара мәктәп музеена бару һәм чәй өстәле артында күңелле хатирәләр белән тәмамланды.

Чарада катнашучыларның барысы да, шул исәптән тамашачылар да, мондый очрашуларның кирәклеген ассызыклады. Алар буыннарны берләштерә, сакчыл мөнәсәбәтләргә, үткәнгә ярдәм итә.

**Галмәтдин СОЛТАНОВ,**
**Суккул авылы хезмәт ветераны.**

***Автор фотосы.***

● ХОКУК ТӘРТИБЕ

# Ришвәт – җинаять эше

**Ярмәкәй районы буенча Дәүләт автоинспекциясе вазифалы затка ришвәт биргән өчен җинаять җаваплылыгы турында кисәтә**




Машина йөртүчеләрнең юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозу очраклары еш була, алар дәүләт автоинспекторына административ материаллар төземичә акча ярдәмендә “мәсьәләне хәл итәргә” тәкъдим итә. Күп кенә гражданнар мондый гамәлләрнең законга каршы килүен белә, әмма мондый очраклар барыбер була. Дәүләт автоинспекциясе кисәтә, юл-патруль хезмәте инспекторларының патруль машинасында видеокүзәтү камералары урнаштырылган, алар булган хәлләрне яздыра.

Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләрен ришвәт алырга омтылу – җинаять – җәзалана торган гамәл, ул “бирүче” өчен генә түгел, ә үз вазифаларын башкаручы зат өчен дә җаваплылыкка китерә.

Автоинспекторлар гражданнарны акчалата ришвәт бирергә тырышмаска чакыра, чөнки РФ ҖК 291 маддәсе нигезендә ришвәт бирү өчен штрафтан башлап, реаль срокка кадәр irектән мәхрүм итү каралган.

● **АВЫЛ, СИНЕҢ КЕШЕЛӘРЕН**

# Яшьләргә һәрнәрсәдә үрнәк

**Рәтамак авылында авыл хуҗалыгы житештерүен оештыручы Миргазыян Мөлек улы Гыйльмановны хөрмәтләделәр. Бу май көннәрендә аңа 85 яшь тулды**

Миргазыян Рәтамак авылында, гаиләдә икенче бала булып туа. Җиде сыйныфны туган авылында тәмамлый, ә урта белемне Иске Турайда ала. Аннары Башкортстан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетында белгечлек ала.

Туган авылында безнең язма герое лаеклы абруй һәм хөрмәт белән файдалана. Ул бөтен гомерен җирдә хезмәт итүгә багышлый: башта гади колхозчы булып эшли, "Рә" колхозында баш агроном, егерме ел бу хуҗалыкны өзлексез җитәкли һәм тагын ун ел рәис урынбасары була. Үзенең кече ватанга армый-талмый хезмәт итүе өчен Миргазыян Гыйльманов БАССРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре дигән мактаулы исемгә, күп кенә медальләргә һәм Мактау грамоталарына лаек була.



Безнең язма героеның гаиләсе бүгенге яшьләр өчен һәрнәрсәдә үрнәк булып тора. Ярты гасырдан артык Гыйльмановлар тынычлыкта һәм татулыкта яшиләр. Хатыны Зөләлә Әхәт кызы белән өч лаеклы бала тәрбияләп үстергәннәр. Барысына да югары белем биргәннәр. Бүгенге көндә аларны дүрт оныгы һәм оныкчыгы сөендерә.

Миргазыян Мөлек улын зур юбилее белән Рәтамак авыл биләмәсе башлыгы Хәбибуллина Р.М., эшләр белән идарә итүче Әхмәтҗанова Г.Н., Рәтамак авылы ветераннар советы рәисе Арсланова Г.М. һәм мәдәни оештыручы Вәлиәхмәтова Ф.Р. котладылар.

**Ачык чыганаклар материаллары буенча Татьяна СЕРГЕЕВА әзерләде.**

● **МӘГАРИФ**

## *Үзгәрешләр вакыты һәм яшьлек тантанасы*

**Башы 1нче биттә.**

Соңгы кыңгырау – мәктәп тормышы дәвамында укучыларның тырыш хезмәтенә йомгак ясау. Күпсанлы тугызынчы һәм унберенче сыйныф укучылары грамоталар һәм Рәхмәт хатлары алдылар. Аларның берсенә фән олимпиадаларында һәм бәйгеләрендә җиңүләре, икенчеләренә спорттагы казанышлары, мәдәни һәм иҗтимагый тормышта актив катнашулары өчен тапшырылды. Бүләкләр коллекциясен туплаучылар да бар иде. Быелгы чыгарылыш сыйныф укучылары – талантлы, югары казанышларга сәләтле һәм максатчан.

Медаль иясе, 2012 елда Ярмәкәй урта мәктәбен тәмамлаган Самат Сәлимовтан иң уңышлы чыгарылыш укучыларына стипендия тапшыру инде яхшы традициягә әверелде. Быел унберенче сыйныф укучылары Самира Локманова, Мурат Миргасыймов һәм Камилә Шәрифуллинага бишәр мең сум акча тапшырылды. Яхшы чыгарылыш укучыларына үзенең премиясен шулай ук билгесез калырга теләгән хәйрияче гамәлгә кертте.









Алып баручылар Нәсибә Мәүлиева белән Гүзәл Хәлиуллинага балалар бакчалары тәрбияләнүчеләре һәм беренче сыйныф укучылары ярдәм итте. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар музыкаль котлаулар һәм биюләр тапшырды, ә беренче сыйныф укучылары – хәзерге югары сыйныф укучыларының киләчәктә алмашынуы – имтиханнарда җиңеләкләр теләп, шигырьләр укыдылар. Һәм, әлбәттә, чыгарылыш сыйныф укучылары үз сүзләрен әйтте. Алар исеменнән Камилә Шәрифуллина, Самира Локманова, Рөстәм Рәхмәтуллин, Эльзар Зарипов һәм Ирина Ганиуллина чыгыш ясады. Әлеге чыгышларда белемнәре өчен укытучыларга һәм ярдәмнәре һәм аңлаулары өчен ата-аналарга рәхмәт сүзләре яңгырады, әлбәттә, һәрвакыт алга барырга һәм туган мәктәпне онытмаска вәгъдәләр бирелде. Бәйрәмдә катнашучыларның барысы өчен дә чыгарылыш укучылары музыкаль котлау, "Туган як" флешмобы башкардылар.

Алда аларның яңа тормыш этабы. Уңышлы булсын өчен, беренче сыйныф укучылары аларга "Киләчәк самолетлары" тапшырдылар. Аннары соңгы кыңгырау чыңлады һәм саубуллашканда мәктәп вальсы яңгырады, чыгарылыш сыйныф укучылары булачак "Чыгарылыш сыйныф укучылары" аллеясына агач үсентеләре утырту һәм тагын бер яхшы традициягә башлангыч бирү өчен кузгалдылар.

**Татьяна СЕРГЕЕВА.**
**Мансур АРСЛАНОВ фотосы.**

# Профилактическое мероприятие «Защита»

**В отделении по делам несовершеннолетних ОМВД России по Ермекеевскому району уделяют особое внимание осуществлению профилактической деятельности, направленной на защиту прав и законных интересов детей и подростков.**

На территории района в соответствии с распоряжением МВД по РБ от 14 мая 2024 г. № 1/3099 и распоряжением начальника ОМВД России по Ермекеевскому району от 22.05.2024 г. № 266 в целях предупреждения преступных посягательств в отношении детей, выявления лиц, совершающих насильственные действия, в том числе родителей, законных представителей, иных членов их семей, а также принятия мер по защите прав и законных интересов несовершеннолетних **с 1 по 10 июня 2024 года проводится оперативно-профилактическое мероприятие «Защита».**

В ходе него сотрудниками полиции совместно с другими субъектами профилактики будет проводиться обход жилого сектора на предмет получения информации о лицах, проживающих с несовершеннолетними, злоупотребляющих спиртными напитками, употребляющих наркотические средства или психотропные вещества, ведущих асоциальный образ жизни, совершающих противоправные деяния в отношении детей, не исполняющих обязанностей по их воспитанию и содержанию. При необходимости будут приниматься меры по устройству детей из таких семей в учреждения здравоохранения и социальной защиты.

Кроме того, осуществляется индивидуально-профилактическая работа с законными представителями, состоящими на учете ОДН, с проведением предупредительно-профилактических бесед, обследований условий проживания детей в указанных семьях. Проводится работа в местах организованного летнего детского отдыха по разъяснению несовершеннолетним их прав, основ безопасного поведения и способах реагирования на противоправные действия со стороны взрослых лиц.

**Альбина ЯНИЕВА,**
**инспектор по делам несовершеннолетних отделения МВД России по Ермекеевскому району, капитан полиции.**

● **К СВЕДЕНИЮ!**

**Управление Россельхознадзора по Республике Башкортостан информирует участников внешней экономической деятельности и лицензиатов, выполняющих работы по карантинному фитосанитарному обеззараживанию о том,** что в связи со вступлением в силу с 01.03.2025 Федерального закона от 25.12.2023 № 652-ФЗ «О внесении изменений в Федеральный закон «О карантине растений» (далее – Закон № 652-ФЗ) статьей 5.2 Федерального закона 21.07.2014 № 206-ФЗ «О карантине растений» (далее – Закон № 206-ФЗ) будет установлено, что по результатам проведения карантинного фитосанитарного обеззараживания в федеральной государственной информационной системе в области карантина растений в электронном виде будет составляться акт карантинного фитосанитарного обеззараживания.

● ЧАРАЛАР

# Тартылу урыны – Бекет аланы

Без барыбыз да беләбез, кайбер табигый пейзажлар, урыннар, киңлекләр бар, анда кеше шатлык дулкынын сизә, ә барлык тискәре уйлар читкә китә.

Бекет авыл клубының мәдәни оештыручысы Наталья Крупкина фикеренчә, авыл янындагы алан шундый урын булып тора. Аны Бекет, аның тирәсендәге торак пунктлар халкы ярата. Бу аланда еш кына халык бәйрәмнәре, күркәм чаралар үткәрелә. Анда катнашучылар аны көч урыны дип атыйлар.

Биредә "Аксаков очрашулары" кысаларында Рус география җәмгыяте делегациясе булды. Кунакларга биредә "Бу авылда" театральләштерелгән спектаклен тәкъдим иттеләр. "Селяночка" вокаль коллективы авыл тарихы һәм аның традицияләре турында сөйләде, халык җырларын башкарды.





Ә шушы көннәрдә Бекет аланында Приют мотоклубы сезоны ачылды. Әлеге чарада Приют бистәсе, Октябрьский, Абдуллино шәһәрләреннән 150дән артык кеше катнашты. Наталья Крупкина сөйләвенчә, ул гомуми заезддан башланды. Аннары мототранспорт белән идарә итү осталыгын күрсәтүче конкурслар һәм уеннар оештырылды. Мотосезонны ачуга кабатланмас энергетиканы "Fractal-cucumber" роктөркеме чыгышы бирде.

Приют бистәсеннән килгән мотозаездлар легендасы Рим Сираев белән аралашу да күңелле сюрприз булды. Яше олы булуга карамастан, ул үзенең легендар "Урал"ында килгән, аңарда ул бөтен илне әйләнеп чыккан һәм чит илләрдә булган.

Мотошоуда катнашучылар әйтүенчә, ул һәркемгә якты эмоцияләр һәм онытылмаслык тәэсирләр бүләк иткән.

● ИСКӘРМӘ ӨЧЕН

## БӘЙРӘМГӘ КОРБАН ЧАЛУ:

### Ветеринария хезмәте кагыйдәләрне үтәргә чакыра

Корбанга чалынырга тиеш хайваннарны махсус урыннарда (идентификация номеры, ташу өчен ветеринария ярдәмче документлары булган) һәм "Корбан бәйрәме" вакытында шәхси куллану өчен суюга билгеләнгән урыннарда сатып алганда түбәндәгеләр киңәш ителә:

- моны чалу пунктларында һәм мәйданчыкларында эшләргә;
- шәхси гигиенаны сакларга;

РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның 26 октябрендәге 626 санлы боерыгы белән расланган биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итүнең ветеринария-санитар кагыйдәләренә ярашлы рәвештә яндыру юлы белән биологик калдыкларны (мәгез, тояк, тире һәм башка калдыклар) юк итүне үткәрергә.

Биологик калдыкларны көнкүреш чүп контейнерларына ташлау һәм аларны күмү өчен чүплекләргә һәм полигоннарга чыгару катгый тыела.

Биологик калдыкларны юк итү бурычы хуҗаларга йөкләнә. Суйганда алынган биологик калдыклар дәүләт ветеринария хезмәте контроле астында утильләштерелә.

Югарыда күрсәтелгән таләпләрне бозган очракта гражданнар административ җаваплылыкка тартылачак.

Район территориясендә эпизоотик һәм ветеринария-санитар иминлекне тәэмин итү максатларында:

халык, мәчет җитәкчеләре, шәхси эшмәкәрләр, корбан хайваннарын китерүче оешмалар арасында хайваннарны сайлап алу, ташу һәм суюда гамәлдәге ветеринария таләпләрен үтәү, шулай ук биологик калдыкларны утильләштерү турында аңлату эшләре алып барырга.

Хайваннар "ВетИС" ФГИСта күренергә һәм исәпкә алынырга тиеш, шулай ук хайваннарны карантинлау кысаларында профилактик, диагностик, лаборатория тикшеренүләре, дәвалау һәм башка ветеринария чаралары бәйрәмгә бер ай кала үткәрелергә тиеш.

Килеп туган сораулар буенча БР Дәүләт ветеринария комитетының кайнар линия: 8-800-77-55-82, ветстанция: 2-23-94, 2-28-16 телефоннарына мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

● ФАҖИГАЛӘР

## Безнең йорт хайваннары

Алар шатлыгыбызның, керемнәребезнең чыганагы да, бәхетсезлек очракларының сәбәбе дә булырга мөмкин. Башинформ хәбәр иткән ике фаҗига барыбызны да уйга сала, хәтта иң зарарсыз хайван да үлемгә китерергә мөмкин. Әгәр дә сез моны практикада күрсәгез, бик ачы була.

Бакалы районында тикшерүчеләр эт һөҗүме аркасында балага үлем факты буенча җинаять эше кузгаткан. Шәхси хуҗалык территориясендә бәйдә торган йорт хайваны ике яшь тә ун айлык кызга һөҗүм итә.

Авыр җәрәхәтләр белән баланы хастаханәгә алып китәләр. Кызганычка каршы, алган җәрәхәтләр үлемгә китергән.

Әбҗәлил районында үтерүче – сыер. Ул яңа гына бозаулаган булган. 74 яшьлек хуҗабикә сарайга кереп, аны сауган, ә чыга башлагач, хайван аны сөзгән. Хатын егылган, ләкин сыер тынычланмаган: аны таптавын һәм сөзүен дәвам иткән.

Пенсионерның кычкыруына аның улы йөгереп килгән, ачулы хайванны куып җибәргән. Кызганычка каршы, зыян күрүче үлемгә китергән авыр җәрәхәтләр алган.

Ике очрак та безгә балаларга, өлкәннәргә бик игътибарлы булырга кирәклеген күрсәтә. Аларны күзәтүсез калдырмау бик мөһим. Йорт хайваннарын да күзәтергә кирәк. Җәйге чорда бу аеруча актуаль.

**Татьяна СЕРГЕЕВА әзерләде.**

● ХӘТЕР

## АНДРЕЕВ Леонид Витальевич

**Көчле авырудан соң 57 яшендә Әфганстанда һәм Чечняда сугыш хәрәкәтләре ветераны Андреев Леонид Витальевич вафат булды.**



